ГЛАВА ЧЕМОДУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Нагорная, д.1а, с. Чемодурово, 423307

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕМОДУРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ
Нагорная ур., 1а нче йорт, Чемодурово авылы, 423307

Тел./факс(885592)3-31-61; E-mail:Chmd.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

От 09.11.2020г. №3

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Алферовка торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Уставы белән, карар итәм:

1. 2020 елның 19 ноябрендә 13:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегенең Алферовка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

1.2Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Алферовка торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының үткәрү вакыты-2020 елның 19 ноябрендә 12.00 сәгатьтән 12.30 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны- Алферовка авылы,Зеленая урамы адресы буенча урнашкан ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

-2020 елның 9 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу

хокукын түбәндәге адрес буенча бирергә: Алферовка авылы, Зеленая урамы, 5 йорт.
- Алферовка торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Алферовка авылы халкына, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән халык җыеннары турында хәбәр итәргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Алферовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел», «Авыл көне» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү;

- Алферовка авылы территориясендә үлән чабу, чүп-чар җыю буенча хезмәт күрсәтү;

- Алферовка авылында юлларны кардан чистарту;

- Алферовка зираты коймаларын алыштыру

- Алферовка авылы зиратына контейнер мәйданчыклары урнаштыру, контейнер, киртәләр алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру,нигез салу, коймалар кую).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Алферовка авылы, Зеленая урамы 5 йорт
-Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырылган: http://aznakaevo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә.
4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык Н.Б.Котельникова